# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән авылы торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында

**2023 елның 16 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән авылында гражданнар җыены

## КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарысаз-Тәкермән авылы Иске Имән авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Сарысаз-Тәкермән торак пункты зираты территориясенә койма тоту өчен төзелеш материаллары сатып алу;

2. СарысазТәкермән торак пункты зиратында хуҗалык йорты төзү өчен төзелеш материаллары сатып алу;

3.Сарысаз-Тәкермән торак пунктнының авыл эчендәге урамы юлларын ремонтлау (вак таш түшәмәле чокырлар ремонтлау, сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

4.Сарысаз-Тәкермән торак пункты урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);

5. Сарысаз-Тәкермән торак пунктында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

6. Рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

7. Сарысаз-Тәкермән пунктында Өлкәннәр көнен үткәрү өчен бүләкләр алу.

3. Әлеге карарны Иске Имән авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында

(https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Ә.Исламова